ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) 5 өлештә «гражданлыгы» сүзеннән соң «(подданлыгы)» сүзен өстәргә;
б) 6 өлештә:
2 пунктта «затлар,» сүзеннән соң «шулай ук хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган, әлеге җинаятьләрне кылган өчен хөкем ителгән затлар – хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган көннән алып биш ел узганчыга кадәр,» сүзләрен өстәргә;
$2^1$ пунктта «$127^2$ статьясындагы беренче өлешендә,» сүзләреннән соң «133 статьяның икенче өлешендә, 134 статьяның беренче өлешендә,» сүзләрен, «затлар» сүзеннән соң «, шулай ук хөкем ителүе кире алынган яисә юкка чыгарылган, әлеге җинаятьләрне кылган өчен ирегеннән мәхрүм итүгә хөкем ителгән затлар» сүзләрен өстәргә;
в) $6^1$ өлештә «$1^1$, $1^2$ һәм $2^1$ пунктларында» сүзләрен «$1^1$, $1^2$, 2 һәм $2^1$ пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) $6^1$ статьяда:

а) 1 өлештә «сайлаучыларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч янаганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә:

1 пунктта «сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенең тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге муниципаль сайлауларга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге муниципаль сайлауларга карата» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди сайлауларга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди сайлауларга карата» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяда:

а) 1 өлешнең өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 12 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяда:

а) 2 өлештә «Муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре, җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссияләре, территория,» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссияләре, территория,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «13 статьясының 8 өлешендә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 өлештә «13 статьясының 8 өлеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) $4^2$ өлештә «13 статьясындагы 8 өлеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, округ комиссиясе, территория, участок комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан икедән береннән күбрәген тәшкил итә алмый. Әлеге нигезләмә аерымланган җирләрдә, торак пунктлардан ерак җирләрдә урнашкан хәрби частьлар территорияләрендә оештырылган сайлау участокларында участок комиссияләрен формалаштырганда исәпкә алынмаска мөмкин.»;

е) 8 өлештә «җирле үзидарә органнары,» сүзләрен, «, җирле үзидарә органы» сүзләрен һәм «муниципаль районның (шәһәр округының) сайлау комиссиясенеке – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан, җирлек сайлау комиссиясенеке – муниципаль район сайлау комиссиясе тарафыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 11 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең,» сүзләрен төшереп калдырырга, «сайлау комиссиясе» сүзләрен «комиссия» сүзенә алмаштырырга;

5) 12 статьяда:

а) 10 өлештә «муниципаль районнар, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округы) сайлау комиссияләренең» сүзләрен «муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр эчендәге район (шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округындагы) җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы территория комиссияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

б) $10^2$ өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны оештыручы комиссия»;

6) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 15 статьяда:

а) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрүне тәэмин итү өчен бер йә берничә махсус территория комиссиясе төзергә хокуклы.»;

8) 16 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенең вәкаләтләре бу муниципаль берәмлек чикләрендә эшләүче участок комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

б) $6^1$ өлештә «Сайлаучылар» сүзе алдыннан «Вахта поселогында,» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Участок комиссиясе, җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссия вәкаләтләрен башкарган очракта, әлеге Кодексның 108 статьясында каралган территория комиссиясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»;

9) 17 статьяда:

а) 5 һәм 6 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 20 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләренең матди (шул исәптән акчалата түләү, башка түләүләр күләме һәм төрләре) һәм социаль тәэминаты дәрәҗәсе Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләрен матди һәм социаль тәэмин итү (шул исәптән медицина, шифаханә-курорт, торак-көнкүреш, пенсия тәэминаты һәм башка төр тәэминат) буенча кирәкле чаралар күрәләр.»;

в) 21 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

10) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «гражданлыгы» сүзеннән «(подданлыгы)» сүзен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы составына үзе билгеләп куелган комиссиянең, шулай ук башка комиссиянең мәнфәгатьләрен үзенә бирелгән ышанычнамә нигезендә судта белдерергә хокуклы.»;

в) 8 өлешнең 1 пунктында «чит ил гражданлыгы» сүзләрен «чит ил гражданлыгы (подданлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 өлештә «комиссия әгъзасын билгеләп куйган» сүзләрен «компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән» сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 өлештә «комиссия әгъзасын билгеләп куйган» сүзләрен «компетенциясенә комиссия әгъзасын билгеләп кую кергән» сүзләренә, «11 – 16» саннарын «11, 12, 14 – 16» саннарына алмаштырырга, «муниципаль район (шәһәр округы) сайлау комиссиясенең яңа әгъзасы – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан, җирлек сайлау комиссиясенең яңа әгъзасы – муниципаль район сайлау комиссиясе (әгәр мондый комиссия төзелмәгән булса, – территория комиссиясе) тарафыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 11 өлештә «, муниципаль берәмлекнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы сайлау комиссиясе рәисе яисә секретаре тиешле» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Хәлиткеч тавыш хокукына ия Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының, әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгәннәреннән тыш, даими (штат) нигездә эшләү мөмкинлеге, шулай ук даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларына акчалата түләү, комиссиянең бу әгъзаларына башка түләүләр күләме һәм төрләре Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

з) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын билиләр. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең даими (штат) нигездә эшләүче әгъзалары дәүләт хакимияте органнарында, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында башка вазыйфалар били алмый, укыту эшчәнлегеннән, фәнни эшчәнлек һәм бүтән иҗат эшчәнлегеннән тыш, эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый. Бу чакта укыту эшчәнлеге, фәнни эшчәнлек һәм бүтән иҗат эшчәнлеге, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, чит дәүләтләр, халыкара оешмалар һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый.»;

и) $13^2$ өлештә «, акцияләргә» сүзен һәм «, акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга;

к) 14 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары әлеге статьяның 11 һәм 12 өлешләрендә саналган затларны матди һәм социаль тәэмин итү (шул исәптән медицина, шифаханә-курорт, торак-көнкүреш, пенсия тәэминаты һәм башка төр тәэминат) буенча кирәкле чаралар күрәләр. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисен, Рәис урынбасарын, секретарен матди тәэмин итү (шул исәптән акчалата түләү, бүтән түләүләр күләме һәм төрләре) һәм социаль тәэмин итү дәрәҗәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән матди һәм социаль тәэмин итү дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаска тиеш. Күрсәтелгән затларга акчалата түләү күләме һәм төрләре, шулай ук башка түләүләр күләме һәм төрләре Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

л) 15 өлештә «Үзләре кергән комиссиянең вәкаләтләре тәмамлануга бәйле рәвештә вәкаләтләр чоры тәмамланган, әлеге комиссиянең яңа составы әгъзалары итеп билгеләнмәгән һәм пенсия яшенә җиткән яисә тиешле вазыйфа буенча вәкаләтләр башкарган чорда хезмәткә сәләтен югалткан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга, муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып санала торган сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган, бу комиссияләрдә даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзаларына» сүзләрен «Үзләре кергән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре чоры тәмамлануга бәйле рәвештә вәкаләтләр чоры тәмамланган әлеге комиссиянең Рәисе, Рәис урынбасары, секретаре дәүләт вазыйфаларын биләгән, әлеге комиссиянең яңа составы әгъзалары итеп билгеләп куелмаган һәм пенсия яшенә җиткән яисә тиешле вазыйфа буенча вәкаләтләр башкарган чорда хезмәткә сәләтен югалткан затларга» сүзләренә алмаштырырга, «, муниципаль берәмлекләр уставларында һәм җирле үзидарә органнарының башка норматив хокукый актларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

м) 19 өлештә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) тиешле комиссиянең, машина тарафыннан укыла торган чыганаклардагы документларны һәм материалларны да кертеп, турыдан-туры сайлауларга бәйле документлары һәм материаллары (шул исәптән сайлаучылар исемлекләре, электрон рәвештә төзелгән исемлекләрне дә кертеп, үзенең булу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гаризалар биргән сайлаучылар хакындагы белешмәләр, имза кәгазьләре, кандидатларның, сайлау берләшмәләренең финанс хисаплары, бюллетеньнәр) белән танышырга һәм шушы документларның, материалларның (бюллетеньнәрдән, сайлаучылар исемлекләреннән, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәреннән дә, имза кәгазьләреннән, федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматны тәшкил итә торган мәгълүматка кертелгән башка документлардан һәм материаллардан тыш) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне раслауны таләп итәргә хокуклы;»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) түбәнгерәк комиссиянең әлеге өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән документлары һәм материаллары белән танышырга һәм шушы документларның, материалларның (бюллетеньнәрдән, сайлаучылар исемлекләреннән, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәреннән дә, имза кәгазьләреннән, федераль законда билгеләнгән тәртиптә конфиденциаль мәгълүматны тәшкил итә торган мәгълүматка кертелгән башка документлардан һәм материаллардан тыш) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне раслауны таләп итәргә хокуклы;»;

5 пунктта «исемлекләре» сүзеннән соң «, шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәре,» сүзләрен өстәргә;

11) 20 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бердәм сайлау округы күрсәткән кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә, тиешенчә кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә документларны биргән көннән алып Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган бер әгъзасын билгеләп куярга хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Бер үк зат киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы итеп бер генә комиссиягә һәм бары тик бер кандидат, бер сайлау берләшмәсе тарафыннан гына билгеләп куела ала.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 һәм $2^1$ өлешләре нигезендә билгеләп куелган киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуксыз була:

1) тавыш бирү йомгаклары турында, сайлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә төзергә;

2) тиешле комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга һәм комиссия карарларына имза салырга;

3) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

Әлеге өлешнең нигезләмәләре киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасының үзе билгеләп куелган комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан әлеге өлештә күрсәтелгән гамәлләр башкарылганда катнашуын кире кагу өчен нигез була алмый.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзасы әлеге Кодексның 18 статьясындагы 19 өлешенең 1 – 4, 6 пунктларында каралган сайлаулар әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасының хокукларына ия була.»;

д) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссияләр әгъзаларының вәкаләтләре чоры тиешле сайлаулар нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көндә туктатыла.»;

е) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр кандидатка аны теркәүдән, ә сайлау берләшмәсенә кандидатлар исемлеген теркәүдән баш тартылса, йә кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү бетерелсә яисә кире кагылса, йә кандидат, кандидатлар исемлеге башка сәбәпләр белән вакытыннан алда төшеп калса, мондый кандидат тарафыннан, мондый кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе тарафыннан билгеләп куелган сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре тиешенчә теркәүдән баш тартылган, теркәү бетерелгән яисә кире кагылган көннән туктатыла, әгәр теркәүдән баш тарту турындагы карар буенча судка шикаять бирелсә, теркәүдән баш тартуның законлы булуы турында суд карары үз көченә кергән көннән йә кандидат, кандидатлар исемлеге башка сәбәпләр белән төшеп калган көннән туктатыла.»;

ж) 9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

12) 21 статьяның 1 өлешендә «югарырак комиссияләр әгъзалары» сүзләрен «югарырак комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары» сүзләренә алмаштырырга;

13) 22 статьяда:

а) $3^1$ өлештә:

«Участок комиссияләренә» сүзләреннән соң «һәм территория комиссияләренә» сүзләрен, «тиешле территориаль комиссиягә,» сүзләреннән соң «округ комиссияләренә күзәтүчеләр билгеләп куйганнары – билгеләп куелган күзәтүчеләр исемлеген округ комиссиясенә,» сүзләрен өстәргә;

«муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссиягә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «комиссиягә тавыш бирү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе ике күзәтүче (берничә көн дәвамында тавыш бирү турында әлеге Кодексның $75^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе ике күзәтүче исәбеннән)» сүзләрен «участок комиссиясенә, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә тавыш бирү бинасында, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрне кабул итү, әлеге беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмә төзү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе өч күзәтүче (әлеге Кодексның $75^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлешендә каралган берничә көн дәвамында тавыш бирү турындагы карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе өч күзәтүче исәбеннән)» сүзләренә алмаштырырга, «Участок комиссиясенә» сүзләреннән соң «, территория комиссиясенә һәм округ комиссиясенә» сүзләрен өстәргә;

в) 6 өлешнең 1 пунктында «исемлекләре,» сүзеннән соң «шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәре,» сүзләрен өстәргә;

14) 27 статьяда:

а) 3 өлештә беренче җөмләгә «(әлеге статьяның $3^4$ өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пункты бозылган очракта, сайлау участокларының исемлеге һәм аларның чикләре аларны төзү өчен каралган тәртиптә мәҗбүри төгәлләштерелергә тиеш.»;

б) $3^1$ өлештә:

2 пунктта «(50гә кадәр һәм аннан да кимрәк)» сүзләрен «(100гә кадәр һәм аннан да кимрәк) йә артуы (3000нән күбрәк)» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «максималь» сүзен төшереп калдырырга;

4 пунктта «максималь» сүзен һәм «өч меңгә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «(шулай ук әлеге статьяның $3^4$ өлешендә каралган очракта)» сүзләрен өстәргә;

в) $3^2$ өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^4$ өлеш өстәргә:

«$3^4$. Казан шәһәрендә, сайлаучылар саны 500 000нән артык булган шәһәр округында, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп һәм алга таба Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, сайлаучылар саны 3000нән артык булган сайлау участоклары төзү (сайлау участоклары исемлеген һәм аларның чикләрен төгәлләштерү) рөхсәт ителә. Бу чакта сайлаучылар өчен иң уңайлы шартларны булдыру тәэмин ителергә тиеш.»;

д) 4 өлештә «(муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 5 өлештә «(муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 28 статьяда:

а) 4 өлештә «айга кимендә бер тапкыр» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм (яисә)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

«$8^1$. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыру тәртибе, федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

16) 29 статьяда:

а) 7 өлештә «(муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 10 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 12 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 13 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $15^1$ өлеш өстәргә:

«$15^1$. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә сайлаучылар исемлеге, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда электрон рәвештә төзелергә, төгәлләштерелергә һәм кулланылырга мөмкин.

Сайлаучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән, төгәлләштерелгән һәм кулланылган очракта, аның күчермәсе тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң ук (тавыш бирүнең соңгы көнендә) сайлаучылар исемлеген кәгазьдә чыгару юлы белән әзерләнә һәм участок комиссиясе рәисе, секретаре имзалары һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана. Әлеге күчермә үзенең юридик көче буенча электрон рәвештәге сайлаучылар исемлегенә тиңдәш була. Күрсәтелгән күчермәне саклау «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Кодекс нигезендә сайлау документларын саклауга карата билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

17) 34 статьяның 9 өлешендәге икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Бу чакта әлеге срокның тәмамлану вакыты булып җирле вакыт буенча 18 сәгать санала.»;

18) 39 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта),» сүзләреннән соң «индивидуаль шәхси счетның иминият номеры,» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешнең 4 пунктында «кандидатныкы булган мөлкәте турында,» сүзләреннән соң «счетлары,» сүзен өстәргә;

в) 3 өлешнең 2 пунктында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга, «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

19) 40 статьяда:

а) 1 өлештә «салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта),» сүзләреннән соң «индивидуаль шәхси счетының иминият номеры,» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешнең 3 пунктында «(шул исәптән уртак милектәге) мөлкәте турында,» сүзләреннән соң «счетлары,» сүзен өстәргә;

20) 44 статьяның $6^1$ өлешендә «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырырга;

21) 45 статьяның 6 өлешендә:

а) «соңга калмыйча» сүзләреннән соң «җирле вакыт белән» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Законда билгеләнгән срокта кандидатлар исемлеген теркәү өчен каралган документларның берсе дә тапшырылмаган очракта, тиешле сайлау комиссиясе сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлегенә кертелгән кандидатларны кандидат статусын югалткан дип тану турында карар кабул итә. Кандидат теркәлү узганчы әлеге Кодексның 53 статьясындагы 1, 2, 4 яисә 5 өлешләрендә каралган очраклар барлыкка килгәндә, ул вафат булган очракта йә законда билгеләнгән срокта кандидатны теркәү өчен тапшырырга кирәкле булган, законда каралган документларның берсе дә тапшырылмаган очракта, тиешле сайлау комиссиясе турыдан-туры күрсәтелгән кандидатны кандидат статусын югалткан дип тану хакында карар кабул итә.»;

22) 46 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Сайлау комиссиясе әлеге Кодексның 39 – 42 статьялары нигезендә тапшырыла торган кандидатлар турындагы белешмәләрнең, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат тарафыннан тапшырыла торган Россия Федерациясе сенаторы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатуралар хакындагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү, әлеге Кодексның 39 статьясындагы 5 өлешендә, 40 статьясындагы $3^3$ өлешендә, 41 статьясындагы $1^3$ өлешендә һәм 42 статьясындагы $2^2$ өлешендә каралган таләпләрнең үтәлешен тикшерү өчен, шул исәптән күрсәтмә белән, тиешле органнарга, учреждениеләргә һәм оешмаларга мөрәҗәгать итә, алар әлеге Кодексның 39 – 42 статьялары нигезендә тапшырыла торган белешмәләрне, шулай ук Россия Федерациясе сенаторы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатуралар турындагы белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре турында – 10 көн эчендә, ә әлеге Кодексның 39 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты, 40 статьясындагы 3 өлешенең 3 пункты (әлеге Кодексның 39 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты таләпләрен үтәү өлешендә әлеге Кодексның 41 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, 42 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты) нигезендә тапшырыла торган белешмәләрне тикшерү һәм әлеге Кодексның 39 статьясындагы 5 өлешендә, 40 статьясындагы $3^3$ өлешендә, 41 статьясындагы $1^3$ өлешендә һәм 42 статьясындагы $2^2$ өлешендә каралган таләпләрнең үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре хакында 20 көн эчендә хәбәр итәргә тиеш. Сайлау комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 10 һәм аннан да азрак көн кала мөрәҗәгать итсә, тиешле органнар, учреждениеләр һәм оешмалар тикшерү нәтиҗәләре турында сайлау комиссиясе билгеләгән срокта хәбәр итәргә тиеш. Кандидатлар турында белешмәләрнең дөреслеген тикшерү бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын һәм (яисә) «Сайлаулар» ДАСны кулланып гамәлгә ашырылса, мондый күрсәтмә

җибәрелмәскә мөмкин, бу чакта мондый тикшерү нәтиҗәләре тиешле органның (учреждениенең, оешманың) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланырга тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^8$ өлеш өстәргә:

«$4^8$. Кандидатның чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик зат йә чит ил агенты функцияләрен башкаручы зат белән аффилиацияләнгән кандидат булуы турындагы белешмәләрне тикшергәндә, сайлау комиссиясе федераль башкарма хакимиятнең коммерциягә карамаган оешмаларны теркәү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органына мөрәҗәгать итә. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә федераль башкарма хакимиятнең коммерциягә карамаган оешмаларны теркәү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы тикшерү нәтиҗәләре турында сайлау комиссиясенә – 10 көн эчендә, ә сайлау комиссиясенең күрсәтмәсе тавыш бирү көненә кадәр 10 һәм аннан да азрак көн кала кергәндә, сайлау комиссиясе билгеләгән срокта хәбәр итәргә тиеш.»;

в) 16 өлешнең 9 пунктында «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырырга;

23) 58 статьяга түбәндәге эчтәлекле $10^4$ өлеш өстәргә:

«$10^4$. Агитация материалында чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән физик затның яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына үзе турында мәгълүмат кертелгән физик затның сүзләре файдаланылган очракта, бу сүзләр хакында алар шушы физик зат тарафыннан әйтелгән дигән мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге мәгълүмат ачыктан-ачык күренеп торырга (аңлаешлы ишетелергә) һәм агитация материалы мәйданының (күләменең) кимендә 15 процентын биләргә тиеш. Агитация материалында мондый сүзләр кулланылган очракта, кандидат, сайлау берләшмәсе, агитация материалын билгеләнгән тәртиптә телерадиотапшырулар оешмасына, вакытлы матбугат басмасы редакциясенә, комиссиягә тапшырганда, чит ил агенты функцияләрен башкаручы физик затлар исемлегенә кертелгән кайсы физик затның яисә чит ил агенты функцияләрен башкаручы чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары реестрына үзе турында мәгълүмат кертелгән кайсы физик затның нинди сүзләре агитация материалында кулланылганы хакында мәгълүмат бирә.»;

24) 60 статьяда:

а) 4 өлештә «матбугат мәйданы бирергә» сүзләреннән соң «, «Интернет» челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру хезмәтләре күрсәтергә» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

«$11^1$. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, вакытлы матбугат басмаларында урнаштыру өчен билгеләнгән агитация материалының күчермәсе, агитация материалы күрсәтелгән оешмага, вакытлы матбугат басмасы редакциясенә җибәрелгәннән (тапшырылганнан) соң һәм ул таратыла башлаганчы, теркәлгән кандидат, сайлау берләшмәсе тарафыннан тиешле агитация материалында кайсы кандидатның (кандидатларның) сурәте файдаланылу (агитация материалында кандидат (кандидатлар) сурәтләре файдаланылган очракта) турындагы мәгълүмат белән бергә тиешле сайлау комиссиясенә тапшырыла.»;

25) 62 статьяда:

а) 4 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче җөмлә өстәргә: «Әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^4$ өлешендә күрсәтелгән сүзләр файдаланылган, вакытлы матбугат басмаларында урнаштырыла торган агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^4$ өлеше нигезендә бу хакта мәгълүмат урнаштырылырга тиеш.»;

26) 63 статьяда:

а) 3 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны уздырганда – территория комиссиясе тарафыннан, ә муниципаль сайлауларны уздырганда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «территория комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны уздырганда – территория комиссиясенә, ә муниципаль сайлауларны уздырганда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә бина бирү факты, аның бирелү шартлары турында, шулай ук агитация чоры дәвамында бу бинаның башка теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә бирелергә мөмкин булуы турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиешләр» сүзләрен «территория комиссиясенә бина бирү факты, аны бирү шартлары турында, шулай ук агитация чоры дәвамында бу бинаның башка теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә кайчан бирелергә мөмкин булуы турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиешләр» сүзләренә алмаштырырга;

27) 64 статьяда:

а) 3 өлештә «әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^3$ өлеше нигезендә бу хакта мәгълүмат булырга тиеш» сүзләрен «, шулай ук әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^4$ өлешендә күрсәтелгән сүзләр файдаланылган агитация материалларында әлеге Кодексның 58 статьясындагы $10^3$ һәм $10^4$ өлешләре нигезендә бу хакта мәгълүмат булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә «10 һәм $10^3$ өлешләрендә» сүзләрен «10, $10^3$ һәм $10^4$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

28) 66 статьяда:

а) 2 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 10 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

29) 72 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктында «муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча территория комиссияләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче җөмләсендә «белгечләрне» сүзеннән соң «комиссияләр билгеләгән срокка, әмма алты айдан да күбрәккә түгел,» сүзләрен өстәргә, өченче җөмләне төшереп калдырырга;

в) 5 өлешнең 2 пунктында «, шул исәптән акцияләре» сүзләрен төшереп калдырырга, «башкача катнашуы турында,» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта,» сүзләрен өстәргә;

30) 75 статьяда:

а) 6 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) фамилиясе, исеме, атасының исеме. Әгәр ике һәм аннан күбрәк кандидатның фамилиясе, исеме һәм аталарының исеме тулысынча туры килсә, кандидатлар турындагы белешмәләр бюллетеньгә кандидатларның туган көннәре буенча урнаштырыла (беренче булып өлкәнрәк кандидат хакында белешмәләр күрсәтелә). Әгәр кандидат сайлау кампаниясе чорында йә сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарылган) көнгә кадәр бер ел дәвамында фамилиясен, яисә исемен, яисә атасының исемен үзгәрткән булса, бюллетеньдә шулай ук аның элеккеге фамилиясе, яисә исеме, яисә атасының исеме күрсәтелә;»;

б) 16 өлештә «гаризалар биргән» сүзләреннән соң «йә вахта ысулы белән эшләүче һәм әлеге Кодексның 29 статьясындагы 17 өлеше нигезендә сайлаучылар исемлегенә керү хокукына ия булган» сүзләрен өстәргә;

31) $75^1$ статьяда:

а) 2 өлештә «референдумнарда» сүзеннән соң «, шул исәптән Татарстан Республикасы чикләрендә дә,» сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлештә «референдумнарда» сүзеннән соң «, шул исәптән Татарстан Республикасы чикләрендә дә,» сүзләрен өстәргә;

в) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Тавыш бирүне үткәрү турында карар әлеге статья нигезендә кабул ителгән очракта, әлеге Кодексның 76[1] статьясындагы 1, 15 һәм 16 өлешләрендә каралган вакытыннан алда тавыш бирү, әлеге Кодексның 77 статьясындагы 18 өлешендә каралган тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү үткәрелми.»;

32) 76 статьяда:

а) 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Сайлауларны оештыручы комиссиянең тиешле карары нигезендә граждан паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры сайлаучылар исемлеген төзегәндә әлеге исемлеккә «Сайлаулар» ДАСтан файдаланып кертелергә мөмкин.», түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Сайлаучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон график имзаны куллану рөхсәт ителә.»;

б) 15 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче һәм башка затлар Россия Федерациясенең сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарын бозса, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан шунда ук читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан (тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмәләрне кабул итү, бу беркетмәләрнең күрсәткечләрен кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү гамәлгә ашырыла торган бинадан) чыгарыла. Участок комиссиясе әгъзасын шушы комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене яисә башка затны тавыш бирү бинасыннан (тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмәләрне кабул итү, бу беркетмәләрнең күрсәткечләрен кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү гамәлгә ашырыла торган бинадан) чыгару хакындагы карар суд тарафыннан участок комиссиясенең (башка комиссиянең) урнашу урыны буенча кабул ителә. Тиешле суд карарын үтәүне хокук саклау органнары тәэмин итә. Хокук саклау органнары шулай ук федераль законнар нигезендә тавыш бирү бинасында һәм сайлау участогы территориясендә гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итә.»;

в) 16[1] өлештә «, шулай ук дистанцион электрон тавыш бирү юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

33) 76[1] статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 өлештә:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә алмаштырырга;

«киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 8 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

е) 9 өлештә «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 10 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

з) 11 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

и) 12 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

34) түбәндәге эчтәлекле $76^2$ статья өстәргә:

«$76^2$ статья. **Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү**

1. Сайлаулар үткәрелгәндә тиешле сайлау комиссиясе карары белән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Әлеге карарда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү сроклары, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү өчен кулланыла торган дәүләт мәгълүмат системалары, шулай ук сайлаучының дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу хокукын бирү шартлары билгеләнергә тиеш.

2. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында тавыш бирү көннәре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда һәм (яисә) Татарстан Республикасы референдумында, җирле референдумда тавыш бирү көннәре белән туры килгән очракта, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү хакындагы карар, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү турындагы карар, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан (җирле үзидарә органнарына сайлауларда җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тәкъдиме буенча) кабул ителә.

4. Федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында элегрәк кулланылган региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне

үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, килештерү таләп ителми, бу чакта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабул ителгән карар турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

5. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү сертификация үткән һәм Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү таләпләренә туры килгән «Сайлаулар» ДАСны, шулай ук башка дәүләт мәгълүмат системаларын, шул исәптән региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системаларын, кулланып үткәрелә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү өчен федераль һәм (яисә) региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системалары кулланылырга мөмкин.

7. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында тавыш бирү көннәре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда һәм (яисә) Татарстан Республикасы референдумында, җирле референдумда тавыш бирү көннәре белән туры килгән очракта, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

8. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларны федераль дәүләт мәгълүмат системаларын кулланып үткәргәндә, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларны региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системасын кулланып үткәргәндә, әлеге статьяның 10 өлешендә каралган таләпләрне исәпкә алган дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

10. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү таләпләрен исәпкә алган дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибенә түбәндәгеләр керергә тиеш:

1) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу турында гариза бирү һәм аны кире алу, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төзү һәм куллану тәртибе һәм сроклары йә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә мондый гариза бирмичә генә катнашу шартлары һәм дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашканнарның исемлеген төзү һәм куллану тәртибе;

2) сайлаучының белешмәләрен тикшерүне һәм сайлаучылар регистры белешмәләре белән чагыштыруны күздә тоткан дистанцион рәвештә электрон

тавыш бирүдә катнашу өчен сайлаучыны аутентификацияләү һәм идентификацияләү тәртибе;

3) сайлаучының дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу тәртибе;

4) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне оештырганда, гамәлгә ашырганда һәм, мондый тавыш бирү үзенчәлекләрен исәпкә алып, аның йомгакларын билгеләгәндә күзәтү мөмкинлеген тәэмин итү тәртибе, шулай ук күзәтүчеләрне билгеләп кую тәртибе;

5) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләгәндә аларны исәпкә алу тәртибе.

11. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән сайлаучы тиешле сайлаучылар исемлегеннән төшереп калдырыла.

12. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу өчен сайлаучы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә билгеләнгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге махсус порталга (шул исәптән махсус мобиль кушымтадан файдаланып) мөрәҗәгать итә һәм аутентификация һәм идентификация, шулай ук шәхесне таныклау процедураларын уза, шуннан соң ул дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдән файдалана ала.

13. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү барышында анонимлаштыру процедурасы башкарыла, ул тәмамланганнан соң, электрон бюллетеньгә күчү башкарыла һәм, кирәкле мәгълүмат, аны тутыру тәртибе белән танышканнан соң, хуплаган позициягә туры килә торган квадратта электрон рәвештә тамга кую юлы белән ихтыяр белдерү мөмкинлеге бирелә. Сайлаучы ихтыяр белдерүне башкарганнан соң, ихтыяр белдерүне үзгәртү (кабат ихтыяр белдерү) рөхсәт ителми. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдән файдаланган сайлаучы сайлау участогында бюллетень алырга хокуксыз. Мондый сайлаучы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә билгеләнгән очракларда турыдан-туры тавыш бирү бинасында яисә башка бинада дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу өчен техник чаралардан файдаланырга мөмкин.

14. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелгәндә ихтыяр белдерүнең анонимлаштырылган нәтиҗәләре, аларны формалаштырган саен, кичектергесез рәвештә шифрлана һәм шифрланган рәвештә тиешле мәгълүмат базасындагы мәгълүмат блоклары чылбырында саклана. Ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен шифрлау шифр ачкычын кулланып гамәлгә ашырыла. Ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен шифр ачкычын кулланып уку мөмкин түгел. Тавыш бирү тәмамланганнан соң ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен уку шифрны ачу ачкычын кулланып башкарыла.

15. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелгәндә сайлаучы тарафыннан ихтыяр белдерүне гамәлгә ашыру һәм сайлаучыларның, ихтыяр белдерүләренең саклана торган нәтиҗәләренең үзгәрмәвен һәм тавыш бирү яшеренлеген үтәүне исәпкә алып, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру мөмкинлеге, шулай ук сайлаучының персональ белешмәләре һәм аның ихтыяр белдерү нәтиҗәсе арасында бәйләнеш билгеле алмау тәэмин ителә.

16. Дистанцион электрон тавыш бирүне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимиятнең иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге органы һәм федераль башкарма хакимиятнең техник разведкаларга каршы тору һәм мәгълүматны техник яклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә билгеләнгән дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны саклау турындагы таләпләрне үтәү тәэмин ителергә тиеш.

17. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә дистанцион электрон тавыш бирүне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда «Сайлаулар» ДАСны, башка дәүләт мәгълүмат системаларын куллану, шулай ук сайлаучыларның персональ белешмәләрен эшкәрткәндә аларның хезмәттәшлеге бары тик сайлау хокукларын гамәлгә ашыру максатларында гына башкарыла.»;

35) 77 статьяда:

а) 6 өлештә «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 14 өлештә «комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга, «комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган кимендә ике әгъзасына, төрле кандидатлар, сайлау берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләп куелган күзәтүчеләргә» сүзләрен «төрле кандидатлар, сайлау берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан билгеләп куелган кимендә ике күзәтүчегә» сүзләренә алмаштырырга, «сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 17 өлештә «, участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары» сүзләрен төшереп калдырырга;

36) 78 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктының дүртенче абзацында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

37) 79 статьяда:

а) 4 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) $5^1$ өлешнең 4 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлешнең бишенче абзацында «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

«$7^1$. Сайлаучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән, тәгалләштерелгән һәм кулланылган очракта, әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләрендә каралган күрсәткечләрне кушу гамәлләре мондый исемлек буенча автомат рәвештә башкарыла.»;

д) 10 өлештә «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 11 өлештә «да, киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына да» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 13 өлештә «барлык бюллетеньнәр» сүзләрен «тиешле сайлау округы буенча тавыш бирү өчен барлык бюллетеньнәр» сүзләренә алмаштырырга;

з) $16^1$ өлештә «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе,» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе,» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

и) 21 өлештә «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә ышанырга хокуклы» сүзләрен төшереп калдырырга;

к) 22 өлештә «Участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларын һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

л) 23 өлештә «да, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да» сүзләрен «, күзәтүчеләр» сүзенә алмаштырырга;

м) $23^1$ өлешнең беренче абзацында «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

н) 30 өлештә «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның» сүзләрен «әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларның» сүзләренә алмаштырырга;

о) 33 өлештә «үзенең киңәш итү хокукына ия әгъзаларына, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең элек расланган беркетмәсен төзегәндә катнашкан башка затларга» сүзләрен «тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең элек расланган беркетмәсен төзегәндә катнашкан затларга» сүзләренә алмаштырырга;

38) 83 статьяның 2 өлешендә «, шулай ук территорияләрендә бердән артык территория комиссиясе төзелгән муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрендә (граждани-хокукый шартнамәләр нигезендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

39) 89 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Тавыш бирү әлеге Кодексның 47 статьясындагы 11 өлеше нигезендә кичектерелеп торган очракта, мондый кичектерелеп торуга кадәр теркәлгән кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме, мондый кичектерелеп торуга кадәр кандидатлар исемлеге теркәлгән сайлау

берләшмәсенең сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 20 процентка кадәр арттырылырга мөмкин.»;

40) 104$^{3}$ статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасын биләгән һәм шул вазыйфасыннан Россия Федерациясе Президенты тарафыннан алынган Россия Федерациясе гражданы Россия Федерациясе Президентының аны вазыйфасыннан алу хакындагы указы үз көченә кергән көннән алып санала торган биш ел дәвамында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат итеп күрсәтелә алмый. Әлеге өлештә күрсәтелгән срок Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар билгеләнгән көнгә кадәр тәмамланырга тиеш.»;

41) 104$^{6}$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Тавыш бирү әлеге Кодексның 47 статьясындагы 11 өлеше нигезендә кичектерелеп торган очракта, мондый кичектерелеп торуга кадәр теркәлгән кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 20 процентка кадәр арттырылырга мөмкин.»;

42) 106 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Тавыш бирү әлеге Кодексның 47 статьясындагы 11 өлеше нигезендә кичектерелеп торган очракта, мондый кичектерелеп торуга кадәр кандидатлар исемлеге теркәлгән сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 20 процентка кадәр арттырылырга мөмкин.»;

43) 107 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) комиссиясе;»;

44) 108 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«108 статья. **Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештырганда территория комиссиясе вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештырганда территория комиссиясе:

1) җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

2) муниципаль берәмлек территориясендә Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары үтәлешен тикшереп тора;

3) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә, кирәкле матбугат продукциясен бастырып чыгаруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

4) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә сайлау алды агитациясе алып бару өчен эфир вакытын һәм матбугат мәйданын теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре арасында бүлеп бирүнең бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

5) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләүнең бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

6) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны үткәргәндә тавыш бирү йомгакларын һәм сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруның бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

7) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанслауны оештыру чараларын гамәлгә ашыра, җирле бюджеттан һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанс белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны бүлә, әлеге акчалардан максатчан файдалануны тикшереп тора;

8) түбәнгерәк комиссияләргә хокукый, ысулый, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

9) җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары хәбәрләрен тыңлый;

10) түбәнгерәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

11) округ комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен билгеләп куя;

12) округ комиссияләре төзелмәгән йә аларның вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә башка комиссияләргә йөкләнмәгән очракларда округ комиссияләре вәкаләтләрен башкара;

13) бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округларының схемасын билгели һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каравына тәкъдим итә;

14) сайлау берләшмәләре тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләрен таныклый;

15) кандидатлар исемлекләрен, шулай ук бердәм сайлау округы буенча күрсәтелгән кандидатларны терки;

16) теркәлгән кандидатлар исемлекләрен бастырып чыгара (халыкка җиткерә);

17) сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларын, финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен терки;

18) сайлау берләшмәләре тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләренә кертелгән теркәлгән кандидатларның кайсысы бердәм сайлау округы буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатлары итеп сайланганын билгели һәм аларга сайлану турында таныклыклар бирә;

19) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатлары итеп сайланган затларның исемлекләрен төзи һәм әлеге исемлекләрне, кирәкле документларны күрсәтелгән органга тапшыра;

20) җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын сайлауларның гомуми нәтиҗәләрен билгели һәм аларны рәсми бастырып чыгара;

21) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Кодекс, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль берәмлек уставы нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

45) 108[1] статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә:

беренче абзацта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

46) 114 статьяның 10 өлешендә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

47) 115 статьяда:

а) 2 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

48) 116 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең беренче абзацында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

49) 117 статьяның 6 өлешендә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясендә» сүзләрен «территория комиссиясендә» сүзләренә алмаштырырга;

50) 118 статьяның 1 өлешендә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

51) 119 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

52) 120 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

53) 121 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

54) 122 статьяда:

а) $3^2$ өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) $3^3$ өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

55) 123 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

56) 126 статьяның 1 өлешендә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

57) 127 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен

«Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

58) 128 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацында «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

59) 128[1] статьяда:

а) 2 өлештә «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 13 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

60) 129 статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15[1] статьяда:

а) 1 пунктта «референдумда катнашучыларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч янаганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди референдумга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендәге теләсә нинди референдумнарга карата» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «сайлау гамәлләрен» сүзләрен «референдум әзерләү һәм үткәрү гамәлләрен» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяда:

а) 1 пунктта «югарырак комиссия әгъзалары» сүзләрен «хәлиткеч тавыш хокукына ия югарырак комиссия әгъзалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7[1] пунктта «Участок комиссияләренә» сүзләреннән соң «һәм территория комиссияләренә» сүзләрен өстәргә;

в) 8 пунктта «комиссиягә иң күбе ике күзәтүче (берничә көн дәвамында тавыш бирү турында әлеге Законның 49[1] статьясындагы 1 яисә 2 пунктында каралган карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе ике күзәтүче исәбеннән) билгеләп куярга хокуклы, алар тавыш бирү бинасында чиратлашып күзәтергә хокуклы» сүзләрен «участок комиссиясенә, территория комиссиясенә тавыш бирү бинасында, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләрне кабул итү, әлеге беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмә төзү бинасында күзәтүне чират буенча башкарырга хокуклы иң күбе өч күзәтүче (әлеге Кодексның 49[1] статьясындагы 1 яисә 2 пунктларында каралган берничә көн дәвамында тавыш бирү турындагы карар кабул ителгән очракта – һәр тавыш бирү көненә иң күбе өч күзәтүче исәбеннән) билгеләп куярга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга, «Участок комиссиясенә» сүзләреннән соң «, территория комиссиясенә» сүзләрен өстәргә;

г) 9 пунктның «а» пунктчасында «исемлекләре,» сүзеннән соң «шул исәптән электрон рәвештә төзелгәннәре,» сүзләрен өстәргә;

3) 25 статьяда:

а) 4 пунктта «айга кимендә бер тапкыр» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә һәм (яисә)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 8[1] пункт өстәргә:

«8[1]. Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыру тәртибе, федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү, гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

4) 26 статьяга түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункт өстәргә:

«$13^1$. Федераль закон нигезендә референдумда катнашучылар исемлеге, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне исәпкә алып, референдум үткәргәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда электрон рәвештә төзелергә, төгәлләштерелергә һәм кулланылырга мөмкин.

Референдумда катнашучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән, төгәлләштерелгән һәм кулланылган очракта, аның күчермәсе тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң ук (тавыш бирүнең соңгы көнендә) референдумда катнашучылар исемлеген кәгазьдә чыгару юлы белән әзерләнә һәм участок комиссиясе рәисе, секретаре имзалары һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана. Әлеге күчермә үзенең юридик көче буенча электрон рәвештәге референдумда катнашучылар исемлегенә тиңдәш була. Күрсәтелгән күчермәне саклау Федераль закон, әлеге Закон нигезендә референдум документларын саклауга карата билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

5) 36 статьяның 3 пунктында «матбугат мәйданы бирергә» сүзләреннән соң «, «Интернет» челтәре басмаларында агитация материалларын урнаштыру хезмәтләре күрсәтергә» сүзләрен өстәргә;

6) 46 статьяның 2 пунктындагы икенче җөмләсендә «белгечләрне» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән срокка, әмма алты айдан да күбрәккә түгел,» сүзләрен өстәргә, өченче җөмләне төшереп калдырырга;

7) 49 статьяның 9 пунктында «гаризалар биргән» сүзләреннән соң «йә вахта ысулы белән эшләүче һәм әлеге Законның 26 статьясындагы 15 пункты нигезендә референдумда катнашучылар исемлегенә керү хокукына ия булган» сүзләрен өстәргә;

8) $49^1$ статьяда:

а) 2 пунктта «референдумнарда» сүзеннән соң «, шул исәптән Татарстан Республикасы чикләрендә дә,» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «референдумнарда» сүзеннән соң «, шул исәптән Татарстан Республикасы чикләрендә дә,» сүзләрен өстәргә;

9) 50 статьяда:

а) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа өченче җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең тиешле карары нигезендә граждан паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры референдумда катнашучылар исемлеген төзегәндә әлеге исемлеккә «Сайлаулар» ДАСтан файдаланып кертелергә мөмкин.», түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Референдумда катнашучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән очракта, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән таләпләрне

исәпкә алып, референдум үткәргәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон график имзаны куллану рөхсәт ителә.»;

б) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче һәм башка затлар Россия Федерациясенең сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарын бозса, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан шунда ук читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан (тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмәләрне кабул итү, бу беркетмәләрнең күрсәткечләрен кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү гамәлгә ашырыла торган бинадан) чыгарыла. Участок комиссиясе әгъзасын шушы комиссия эшендә катнашудан читләштерү, күзәтүчене яисә башка затны тавыш бирү бинасыннан (тавыш бирү йомгаклары хакындагы беркетмәләрне кабул итү, бу беркетмәләрнең күрсәткечләрен кушу һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү гамәлгә ашырыла торган бинадан) чыгару хакындагы карар суд тарафыннан участок комиссиясенең (башка комиссиянең) урнашу урыны буенча кабул ителә. Тиешле суд карарын үтәүне хокук саклау органнары тәэмин итә. Хокук саклау органнары шулай ук федераль законнар нигезендә тавыш бирү бинасында һәм референдум участогы территориясендә гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итә.»;

в) $13^1$ пунктта «, шулай ук дистанцион электрон тавыш бирү юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) түбәндәге эчтәлекле $50^2$ статья өстәргә:

«$50^2$ статья. **Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү**

1. Референдум үткәрелгәндә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Әлеге карарда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү сроклары, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү өчен кулланыла торган дәүләт мәгълүмат системалары, шулай ук референдумда катнашучының дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу хокукын бирү шартлары билгеләнергә тиеш.

2. Федераль закон нигезендә, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында тавыш бирү көннәре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда һәм (яисә) Татарстан Республикасы референдумында, җирле референдумда тавыш бирү көннәре белән туры килгән очракта, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү хакындагы карар, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

3. Референдумда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү турындагы карар, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

4. Федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында элегрәк кулланылган региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, килештерү таләп ителми, бу чакта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабул ителгән карар турында Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

5. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү сертификация үткән һәм Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү таләпләренә туры килгән «Сайлаулар» ДАСны, шулай ук башка дәүләт мәгълүмат системаларын, шул исәптән региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системаларын, кулланып үткәрелә.

6. Референдумда дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү өчен федераль һәм (яисә) региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системалары кулланылырга мөмкин.

7. Федераль закон нигезендә, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда һәм (яисә) Россия Федерациясе референдумында тавыш бирү көннәре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда һәм (яисә) Татарстан Республикасы референдумында, җирле референдумда тавыш бирү көннәре белән туры килгән очракта, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

8. Федераль закон нигезендә, референдумны федераль дәүләт мәгълүмат системаларын кулланып үткәргәндә, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

9. Референдумны региональ (республика) дәүләт мәгълүмат системасын кулланып үткәргәндә, әлеге статьяның 10 пунктында каралган таләпләрне исәпкә алган дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

10. Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне үткәрү таләпләрен исәпкә алган дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибенә түбәндәгеләр керергә тиеш:

а) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу турында гариза бирү һәм аны кире алу, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төзү һәм куллану тәртибе һәм сроклары йә дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә мондый гариза бирмичә генә катнашу шартлары һәм дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашканнарның исемлеген төзү һәм куллану тәртибе;

б) референдумда катнашучының белешмәләрен тикшерүне һәм референдумда катнашучылар регистры белешмәләре белән чагыштыруны күздә тоткан дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу өчен референдумда катнашучыны аутентификацияләү һәм идентификацияләү тәртибе;

в) референдумда катнашучының дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу тәртибе;

г) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүне оештырганда, гамәлгә ашырганда һәм, мондый тавыш бирү үзенчәлекләрен исәпкә алып, аның йомгакларын билгеләгәндә күзәтү мөмкинлеген тәэмин итү тәртибе, шулай ук күзәтүчеләрне билгеләп кую тәртибе;

д) дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм референдум нәтиҗәләрен билгеләгәндә аларны исәпкә алу тәртибе.

11. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучы тиешле референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла.

12. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу өчен референдумда катнашучы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә билгеләнгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге махсус порталга (шул исәптән махсус мобиль кушымтадан файдаланып) мөрәҗәгать итә һәм аутентификация һәм идентификация, шулай ук шәхесне таныклау процедураларын уза, шуннан соң ул дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдән файдалана ала.

13. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү барышында анонимлаштыру калдыру процедурасы башкарыла, ул тәмамланганнан соң, электрон бюллетеньгә күчү башкарыла һәм, кирәкле мәгълүмат, аны тутыру тәртибе белән танышканнан соң, хуплаган позициягә туры килә торган квадратта электрон рәвештә тамга кую юлы белән ихтыяр белдерү мөмкинлеге бирелә. Референдумда катнашучы ихтыяр белдерүне башкарганнан соң, ихтыяр белдерүне үзгәртү (кабат ихтыяр белдерү) рөхсәт ителми. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдән файдаланган референдумда катнашучы референдум участогында бюллетень алырга хокуксыз. Мондый референдумда катнашучы дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү тәртибендә билгеләнгән очракларда турыдан-туры тавыш бирү бинасында яисә башка бинада дистанцион рәвештә электрон тавыш бирүдә катнашу өчен техник чаралардан файдаланырга мөмкин.

14. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелгәндә ихтыяр белдерүнең анонимлаштырылган нәтиҗәләре, аларны формалаштырган саен, кичектергесез рәвештә шифрлана һәм шифрланган рәвештә тиешле мәгълүмат базасындагы мәгълүмат блоклары чылбырында саклана. Ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен шифрлау шифр ачкычын кулланып гамәлгә ашырыла. Ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен шифр ачкычын кулланып уку мөмкин түгел. Тавыш бирү тәмамланганнан соң ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен уку шифрны ачу ачкычын кулланып башкарыла.

15. Дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү үткәрелгәндә референдумда катнашучы тарафыннан ихтыяр белдерүне гамәлгә ашыру һәм референдумда катнашучыларның, ихтыяр белдерүләренең саклана торган нәтиҗәләренең үзгәрмәвен һәм тавыш бирү яшеренлеген үтәүне исәпкә алып, дистанцион рәвештә электрон тавыш бирү йомгаклары турындагы белешмәләрне формалаштыру мөмкинлеге, шулай ук референдумда катнашучының персональ белешмәләре һәм аның ихтыяр белдерү нәтиҗәсе арасында бәйләнеш билгели алмау тәэмин ителә.

16. Дистанцион электрон тавыш бирүне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимиятнең иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге органы һәм федераль башкарма хакимиятнең техник разведкаларга каршы тору һәм мәгълүматны техник яклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан аларның вәкаләтләре чикләрендә билгеләнгән дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны саклау турындагы таләпләрне үтәү тәэмин ителергә тиеш.

17. Федераль закон нигезендә дистанцион электрон тавыш бирүне оештырганда һәм гамәлгә ашырганда «Сайлаулар» ДАСны, башка дәүләт мәгълүмат системаларын куллану, шулай ук референдумда катнашучыларның персональ белешмәләрен эшкәрткәндә аларның хезмәттәшлеге бары тик референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында гына башкарыла.»;

11) 51 статьяда:

а) 6 пунктта «киңәш итү тавышы хокукына ия участок комиссиясе әгъзаларына һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 14 пунктта «референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга, «референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган кимендә ике әгъзасына, инициатив төркем һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәре, иҗтимагый берләшмәләр билгеләгән күзәтүчеләргә» сүзләрен «инициатив төркем һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәре, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан билгеләп куелган кимендә ике күзәтүчегә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 17 пунктта «киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 53 статьяда:

а) 6 пунктның бишенче абзацында «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$. Референдумда катнашучылар исемлеге электрон рәвештә төзелгән, төгәлләштерелгән һәм кулланылган очракта, әлеге статьяның 5 һәм 6 пунктларында каралган күрсәткечләрне кушу гамәлләре мондый исемлек буенча автомат рәвештә башкарыла.»;

в) 9 пунктта «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 10 пунктта «да, киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына да» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 12 пунктта «барлык бюллетеньнәр» сүзләрен «тиешле референдум округы буенча тавыш бирү өчен барлык бюллетеньнәр» сүзләренә алмаштырырга;

е) 19 пунктта «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга хокуклы» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 20 пунктта «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларын һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 21 пунктта «шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары» сүзләрен «күзәтүчеләр» сүзенә алмаштырырга;

и) 22 пунктның беренче абзацында «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр» сүзләрен «күзәтүчеләр,» сүзенә алмаштырырга;

к) 29 пунктта «участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларның» сүзләрен «әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затларның» сүзләренә алмаштырырга;

л) 35 пунктта «тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе тарафыннан элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан затларга, киңәш бирү тавышы хокукына ия башка әгъзаларына» сүзләрен «тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең элек расланган беркетмәсен төзегәндә катнашкан затларга» сүзләренә алмаштырырга;

13) 54 статьяда:

а) 6 пунктта «беркетмәне төзегән территория комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 8 пунктта «үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 9 пунктта «тиешле референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 5 пунктында «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяда:

а) 4 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итә, инициатив төркем мөрәҗәгать иткән көннән ул референдум комиссиясе буларак эшли» сүзләрен «территория комиссиясенә мөрәҗәгать итә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) 11 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

д) 12 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14 статьяда:

а) $6^1$ пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяда:

а) 1 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә» сүзләрен «территория комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 14 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен «территория комиссиясенең» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә, «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен «территория комиссиясендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяда:

а) 1 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә, «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары» сүзләрен «Территория комиссиясе карары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 18 статьяның 4 пунктында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

7) $18^1$ статьяда:

а) 1 пунктта «референдумда катнашучыларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч янаганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктта «референдумны оештыручы сайлау комиссиясенең тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге референдумга кагылышлы дәлилләнгән тәкъдиме буенча» сүзләрен «тиешле муниципаль берәмлек территориясендәге референдумга карата» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «сайлау гамәлләрен» сүзләрен «референдум әзерләү һәм үткәрү гамәлләрен» сүзләренә алмаштырырга;

8) 19 статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территория комиссиясе;»;

б) 10 пунктта «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территория комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

9) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Территория комиссиясе вәкаләтләре**

Референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештырганда территория комиссиясе:

а) референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

б) муниципаль берәмлек территориясендә Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукы үтәлешен тикшереп тора;

в) муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә органнарына референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә, кирәкле матбугат продукциясен бастырып чыгаруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

г) муниципаль берәмлек территориясендә референдум үткәргәндә референдум мәсьәләләре агитациясе алып бару өчен эфир вакытын һәм матбугат мәйданын референдум үткәрү буенча инициатив төркем һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәре арасында бүлеп бирүнең бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

д) муниципаль берәмлек территориясендә референдум үткәргәндә тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең, референдум нәтиҗәләрен билгеләүнең бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

е) муниципаль берәмлек территориясендә референдум үткәргәндә тавыш бирү йомгакларын һәм референдум нәтиҗәләрен бастырып чыгаруның бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын күрә;

ж) муниципаль берәмлек территориясендә референдумнар әзерләүне һәм үткәрүне финанслауны оештыру чараларын гамәлгә ашыра, җирле бюджеттан һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджетыннан референдум әзерләүне һәм үткәрүне финанс белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларны бүлә, әлеге акчалардан максатчан файдалануны тикшереп тора;

з) түбәнгерәк комиссияләргә хокукый, ысулый, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

и) референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары хәбәрләрен тыңлый;

к) түбәнгерәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

л) инициатив төркемне терки;

м) түбәнгерәк референдум комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен раслый;

н) референдумда катнашучыларга референдум әзерләү һәм үткәрү турында хәбәр бирүне тәэмин итә;

